РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЛЬМЕТЬЕВСКА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» июля 2025 ел г. Альметьевск № 11

Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлегe территориясе чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәгә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2024 елның 3 маендагы 06 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

«Татарстан Республикасының территориаль иҗтимагый үзидарә системасының территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен башкару өлешен үстерүгә юнәлдерелгән чаралар уздыругаТатарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 31 октябрендәге 988 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәгә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслаутурында» 2024 елның 3 маендагы 06 номерлы карарына түбәндәге (Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 15 июлендәге 10 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) үзгәрешне кертергә:

карарның 2 нче кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Шәһәр
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Р. Фәсхетдинов

Р.05-12060/12
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
ГОРОДА
АЛЬМЕТЬЕВСКА
ИНН 1644035830
КПП 164401001
ОГРН 1051605067183

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«29» июль 2025 ел № 11
карары белән расланган
2 нче кушымта

Әлмәт шәһәре территориаль иҗтимагый үзидарәләре җитәкчеләренә субсидияләр бирү комиссиясе составы

Фәсхетдинов И.Р. - комиссия рәисе, шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе;
Жалнин Н.А. - комиссия секретаре, Әлмәт шәһәре ТИҮ җитәкчесе (килешү буенча);
комиссия әгъзалары:
Краснов Д.В. - «Үсеш департаменты» муниципаль автоном учреждениесенең җитештерү буенча директор урынбасары (килешү буенча);
Шәйдуллина З.Р. - Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча).

Аппарат җитәкчесе А.Ә. Юнысов